ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында» 563-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында» 563-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 6 июне
№ 2478-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Л.А. Якунин,
К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына $9^2$ кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), $7^1$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

$7^1$. I-муниципаль берәмлегенә башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга субвенциянең күләмен билгеләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$S_K = (T_{кр1} \times Q_1 \times N_м + T_{кр2} \times Q_2 \times N_м) \times (1+S_{взн}/100\%),$$

монда:

$T_{кр}$ – халык саны 100 мең кешедән күбрәк булган торак пунктларда башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели торган күләме;

Q – i-муниципаль берәмлегендә халык саны 100 мең кешедән күбрәк булган

торак пунктларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү ала торган педагогика хезмәткәрләренең фаразлана торган саны;

$N_м$ – башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләр бирелә торган елдагы айлар саны;

$T_{кр2}$ – халык саны 100 мең кешедән азрак булган торак пунктларда башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шулай ук җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели торган күләме;

$Q_2$ – i-муниципаль берәмлегендә халык саны 100 мең кешедән азрак булган торак пунктларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы тарафыннан башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүче уку-укыту программаларын, шул исәптән җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын, гамәлгә ашыручы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү ала торган педагогика хезмәткәрләренең фаразлана торган саны;

$S_{взн}$ – мәҗбүри пенсия иминиятенә, мәҗбүри социаль иминияткә, мәҗбүри медицина иминиятенә иминият кертемнәре тарифларының берләштерелгән күләме, процентларда.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә 2024 елның 29 февралендәге Юлламасын (алга таба – Президент юлламасы), Россия Федерациясе Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасын гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган 2024 елның 30 мартындагы ПР-616 номерлы йөкләмәләр исемлегенең (алга таба – йөкләмәләр исемлеге) 11 пунктындагы «р» пунктчасын үтәү кысаларында эшләнде.

Президент Юлламасы һәм йөкләмәләр исемлеге нигезендә, 2024 елның 1 мартыннан башлап башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләү һәм кимендә 100 мең халкы булган торак пунктларда (шәһәр, район үзәкләре, поселоклар, авыллар) урнашкан урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге (кураторлыгы) өчен айлык акчалата түләү күләме 10 мең сумга кадәр артырга тиеш.

Түләүне финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан бирелә торган башка бюджетара трансфертлар тора. Татарстан Республикасында муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында сыйныф җитәкчелеге өчен түләүләр Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга субвенцияләр бирү юлы белән тәэмин ителә. Субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы (алга таба – Методика) Татарстан Республикасы Бюджет кодексына 9.2 кушымтада бирелә.

Президент Юлламасын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында бер муниципаль берәмлек кысаларында сыйныф җитәкчелеге өчен түләүләр күләме дифференциацияле булганга (ягъни 100 мең кешедән артык халкы булган торак пунктлар өчен элекке күләмдә, ягъни, 5 мең сум кала, ә халкы 100 мең кешегә кадәр булган торак пунктлар өчен 10 мең сумга кадәр арттырыла), Методикага Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләр күләмен исәпләү формуласын төгәлләштерү өлешендә тиешле үзгәрешләр кертергә кирәк.

Сыйныф җитәкчелеге өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 августындагы 671 номерлы карары белән билгеләнгән түләүләр күләме 2024 елның 22 маендагы 352 номерлы карар белән Президент Юлламасы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү, Россия Федерациясе субъектлары һәм Байконур шәһәре дәүләт мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә һәм

башлангыч гомуми белем, төп гомуми белем бирү уку-укыту программаларын, урта гомуми белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә айлык акчалата түләүне тәэмин кагыйдәләрен раслау турында» (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2028 елның 29 мартындагы 398 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 2021 елның 21 декабрендәге 2382 номерлы карары нигезендә төгәлләштерелде.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми. Педагогика хезмәткәрләренә сыйныф җитәкчелеге өчен айлык акчалата түләүне финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе субъектларына федераль бюджеттан бирелә торган бюджетара трансфертлардан гыйбарәт.